**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Татар Шуганы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татар Шуганы авылы №136 «19» декабрь 2024 ел

Татар Шуганы авыл җирлегенең аерым мәсьәләләрен хәл итү өчен вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль законның 6 октябрендәге 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Уставы нигезендә

Татар Шуганы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслауны;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләүне.

2. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәр кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советының 2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакындагы карар проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карарга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә” түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakaevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рэис Хэертдинов М.Ш.